Килешенде:______________
Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты
Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе башлыгы
Р.Н.Хузин

Раслыйм:________________
14 нче балалар-яшүсмерләр үзәге
директоры Н.А.Рахматуллина

# «Татар малае -2020» шәһәр бәйгесенең нигезләмәсе

**Бәйгене оештыручылар:** Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе, 14 нче балалар-яшүсмерләр үзәге, балалар –яшүсмерләр иҗтимагый оешмалар бүлеге.

**Максат**: Милли-мәдәният һәм сәнгать өлкәсендә сәләтле ир балаларны ачыклау, аларга шул юнәлештә үсеп китәргә ярдәм итү, татар халкының йолаларына, гореф-гадәтләренә кызыксыну уяту аша милли үзаң тәрбияләүгә шартлар тудыру.

**Бурычлар**:

1. Мәктәп программалары нигезендә үзләштергән белемнәрне киңәйтү һәм тирәнәйтү.
2. Җыр, бию, нәфис сүз буенча балаларның иҗади сәләтләрен үстерү.
3. Укучыларның дәресләрдән тыш вакытларын файдалы итеп оештыру, татар халкының йолаларына, гореф-гадәтләренә кызыксыну уяту.

**Катнашучылар**: шәһәребез мәктәпләренең 1-4 нче, 5-8 нче сыйныфында укучы ир балалар.

Катнашучыларга таләпләр**:**

а) тел белү дәрәҗәсе;
б) бәйгедә бирелгән юнәлешләрдә күрсәткән белеме;
в) төрле яклап ачылган таланты (җыр, биюү,сөйләм осталыгы);
г) сәхнәдә үз-үзен тотышы;
е) сәхнә киеме (миллилек).

**Бәйгене оештыру тәртибе:**

Бәйге 3 турдан тора.

**1 тур- мәктәпләрдә 14.01.2020 - 25.01.2020 кадәр үтә.**

Монда һәрбер теләк белдергән 1-4 нче,5-8 нче сыйныф малае катнаша ала. Бу турда укучылар үзләре белән таныштыра, талантын күрсәтә.Мәктәп теләге буенча бәйгегә интеллектуальбиремнәр кертә ала.

**2 тур- шәһәр бәйгесенә сайлап алу (гыйнварь-февраль)**

Сайлап алу турына мәктәп турында җиңү яулаган укучы катнаша.(**Һәр мәктәптән 1 генә укучы! Соңгы ике елда бәйгенең җиңүчеләре катнашмый.**)

Икенче турда катнашу өчен **30.01.20** кадәр **odmoo.saifullina@yandex.ru** адресына заявка җибәрергә кирәк.

**Заявка формасы:**

| **Мәктәп №** | **Катнашучының исеме,фамилиясе, сыйныфы** | **җаваплы укытучы, телефон номеры** |
|---|---|---|
| | | |

**Сайлап алу туры ике өлештән тора**.

*<u>1-4 сыйныфлар өчен</u>*

**1) портфолио бәйгесе** – (2 нче турга заявка биргән һәр укучы **01.02.20** кадәр 14 нче балалар-яшүсмерләр үзәгенә (Чулман проспекты ,44/16 йорт,309 кабинетка) үзенең портфолиосын тапшырырга тиеш;

**ПОРТФОЛИО**

**1 бүлек «Минем портрет».**

- укучының шәхси мәгълүматлары (личные данные учащегося);
- укучының автобиографиясе;
- яраткан шөгыле, кызыксынулары(хобби)

**2 бүлек «Минем гаиләм»:**

- гаилә традицияләре;
- күмәкләшеп тормышка ашырылган проектлар.

**3 бүлек «Шәхси документлар».**

- укучының рәсми документлар исемлеге (перечень представленных в Портфолио официальных документов);
- укучының төрле өлкәдә ирешкән уңышлары өчен алган сертификатлары, мактау кәгазьләре, дипломнары (все имеющиеся у школьника сертифицированные документы, подтверждающие индивидуальные достижения обучающихся в различных видах деятельности; грамоты, дипломы за участие в предметных олимпиадах различного уровня, конкурсах, конференциях и т.п.)
- рәхмәт хатлары

**4 бүлек «Минем эшләрем»**.

- укучының татар халкының милли традицияләрен, йолаларын, гореф-гадәтләрен өйрәнү,саклау; татар телен үстерүгә юнәлтелгән эшләр исемлеге (перечень представленных обучающимся проектных, исследовательских, творческих работ направленных на изучение и сохранение национальных традиций, обычаев татарского народа и повышение статуса родного языка (рефераты, сочинения, рисунки, проектные работы, статьи из газет, издаваемых в школе и вне ее);
- өстәмә белем бирү учреждениеләрендә шөгыльләнүе турында мәгълүмат (сведения о занятиях обучающегося в учреждениях дополнительного образования, на различных учебных курсах);
- "Минем мәктәп һәм мәктәптән тыш чараларда катнашуым" (таблица «Мое участие в школьных и внешкольных мероприятиях», в которой учащийся фиксирует все виды творческой деятельности на протяжении установленного срока ведения Портфолио);
- укучының иҗтимагый эшләре турында мәгълүмат (сведения об общественной деятельности учащегося)

- **5 бүлек «Миңа бәяләмә» (Портфолио отзывов)** .
- әти-әнием, туганнарым минем хакта...;
- классташларым минем хакта...;
- укытучыларым минем хакта....

**Портфолионы бәяләү критерийлары:**

1. Җыйнаклык һәм эстетик бизәлеш (Аккуратность и эстетичность оформления)
2. Күрсәтмәлелек (Наглядность)
3. Структуралык (Структурированность)
4. Эчтәлеге, төгәллеге (Содержательность)
5. Бизәлеш ысулы (Единый стиль оформления)

**2) визитка бәйгесе -12-14.02.2020 (график буенча)**

(14 нче балалар һәм яшьләр үзәгенең актлар залында үтәчәк) "Татар теле минем туган телем, бәхетем ул, сүнмәс шатлыгым" темасы астында 5 минутлык иҗади визитка әзерләргә. Визиткада укучының сыйныфташлары, әти-әнисе,укытучылар катнашырга мөмкин.

**Визитка бәйгесен бәяләү критерийлары:**

1) катнашучының сөйләм техникасы, дикция, тел байлыгы;
2) катнашучының сәхнәдә үз-үзен тотышы;
3) катнашучының актерлык һәм сөйләм осталыгы;
4) чыгышның үзенчәлеге;
5) чыгышның эчтәлеге катнашучының яшь үзенчәлегенә туры килүе;
6) чыгышның камиллеге, тема ачылышы;
7) чыгышның эстетик бизәлеше.

## *5-8 сыйныфлар өчен*

**1) эссе бәйгесе**- (2 нче турга заявка биргән һәр укучы **01.02.20** кадәр 14 нче балалар-яшүсмерләр үзәгенә (44/16) 309 кабинетка бирелгән теманың берсенә эссе тапшырырга тиеш;

Эссе темалары:

1. Җиде яктан җыелып килгән җиде ятның, язмышларын бергә җыйды данлы КамАЗ (КамАЗ га - 50)
2. Сезнең тормыш- үзе батырлык (КамАЗ тарихында танылган кешеләр)
3. Бурычлы без сезгә, Ветераннар!( Бөек җиңүнең 75 еллыгы)
4. Ә аналар көтте улларын... !( Бөек җиңүнең 75 еллыгы)
5. Туган ягым гөлләр иле. (ТАССР ның 100 еллык юбилеена багышлап)
6. Көйнең, телнең, гореф гадәтләрнең,
   Бар үз моңы, бар үз хисләре.

**2) визитка бәйгесе** – (февраль аенда14 нче балалар һәм яшьләр үзәгенең актлар залында үтәчәк)

“Татар булып тудым-бәхетле мин, татарлыгым минем-иманым” темасы астында 5 минутлык иҗади визитка әзерләргә. Визиткада укучының сыйныфташлары, әти-әнисе,укытучылар катнашырга мөмкин.

**Визитка бәйгесен бәяләү критерийлары**:

1) катнашучының сөйләм техникасы, дикция, тел байлыгы;
2) катнашучының сәхнәдә үз-үзен тотышы
3) катнашучының актерлык һәм сөйләм осталыгы;
4) чыгышның үзенчәлеге;
5) чыгышның эчтәлеге катнашучының яшь үзенчәлегенә туры килүе;
6) чыгышның камиллеге, тема ачылышы;
7) чыгышның эстетик бизәлеше.

Сайлап алу турының ике өлешен уңышлы узып иң күп балл җыйган 10 укучы финал ярышларына үтәчәк.

**3 тур- финал ярышы -апрель** (1нче шәһәр балалар һәм яшьләр иҗат сараенда үтәчәк)

Финал 3 бәйгедән тора.

**1)иҗади визитка**

Конкурсант индивидуаль яки ярдәмчеләр белән (визиткада башка укучылар, әти-әниләр, укытучылар катнаштырырга мөмкин) **5 минут** эчендә үзе турында, татар теленә, туган ягына мөнәсәбәтен чагылдырып, үзенең талантын күрсәтергә тиеш.

**2)интелектуаль бәйге.** Бу бәйгедә конкурсант түбәндәге бирелгән юнәлешләр буенча төзелгән сорауларга җавап бирергә тиеш булачак. Һәр юнәлеш 5 сораудан тора.

- КамАЗ-50;
- ТАССР ның 100 еллык тарихы
- Бөек җиңүгә 75 ел
- Татар халкының гореф-гадәтләре, йолалары, бәйрәмнәре

**3)импровизация –** конкурсантның татар телендә иркен аралашу, үз фикерен җиткерә алу дәрәҗәсен бәяләү конкурсы. Һәр финалист бирелгән темага жюри әгъзаләре алдында 1 минут сүз тотарга тиеш.

**Импровизация конкурсы темалары:**

1. Кешеләрдәге матур сыйфатлар;
2. Китап – ул хәзинә;
3. Хезмәт кешене бизи;
4. Илдә тынычлык булсын;
5. Туган телемне яратам;
6. Гаиләм – җылы учагым;
7. Дуслык – бөек көч;
8. Туган ягым табигате;
9. Минем киләчәк һөнәрем;
10. Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз;

**Бәйгенең нәтиҗәләре һәм бүләкләнү:**

Бәйгедә катнашачулар түбәндәге номинацияләрдә бүләкләнәләр:

- 1че урын - «Татар малае - 2020»;
- 2 нче урын;
- 3нче урын;
- «Иң талантлы малай»;
- «Иң матур сәхнә образы өчен»;
- «Иң милли җанлы малай»;
- «Иң камил малай»;
- «Милли традицияләрдә тәрбияләнгән малай»;
- «Иң оста телле малай»;
- «Иң акыллы малай»;

**Телефон: 8-917-241-50-64  Гөлкәй Фәрит кызы**

**1-4 сыйныф**

| |
|---|
| **Кешеләрдәге матур сыйфатлар** |
| **Китап – ул хәзинә** |
| **Хезмәт кешене бизи** |
| **Илдә тынычлык булсын** |
| **Туган телемне яратам** |
| **Гаиләм – җылы учагым** |
| **Дуслык – бөек көч** |
| **Туган ягым табигате** |
| **Минем киләчәк һөнәрем** |
| **Мин президент/тылсымчы булсам** |

**5-8 сыйныф**

| |
|---|
| **Кешеләрдәге матур сыйфатлар** |
| **Китап – ул хәзинә** |
| **Хезмәт кешене бизи** |
| **Илдә тынычлык булсын** |
| **Туган телемне яратам** |
| **Гаиләм – җылы учагым** |
| **Дуслык – бөек көч** |
| **Туган ягым табигате** |
| **Минем киләчәк һөнәрем** |
| **Мин президент/тылсымчы булсам** |

"Татар малае - 2019"

# 1

"Татар малае - 2019"

# 2

"Татар малае - 2019"

# 3

"Татар малае - 2019"

# 4

"Татар малае - 2019"

# 5

"Татар малае - 2019"

# 6